**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«08» октябрь 2021 ел** **№ 246**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 25 декабрендәге 358 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керем күләмнәрен 2021 елга билгеләү турында» карарына һәм күрсәтелгән керемнәрдән, максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәренә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 11 декабрендәге 1130 номерлы «2021 елга Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керем күләмнәренең планлы күрсәткечләрен һәм максатчан сарыф ителергә тиешле керемнәрдән тыш, күрсәтелгән керемнәрдән хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен билгеләү турында» карарын үтәү йөзеннән карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 25 декабрендәге 358 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керем күләмнәрен 2021 елга билгеләү һәм турында күрсәтелгән керемнәрдән, максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәренә үзгәрешләр кертү хакында" карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт белән тулыландырырга:

«1.1. Күрсәтелгән учреждениеләр тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрдән административ-идарә персоналының хезмәт хакын түләүгә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының бюджет учреждениеләре тарафыннан юлланган чыгымнар күләме әлеге карарның 1 пункты нигезендә хезмәт хакы

түләүгә җибәрелә торган күрсәтелгән керемнәр күләменең 30 процентыннан артыграк була алмый дип билгеләргә.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад һәм финанслар буенча урынбасары О.Н.Газизовага йөкләргә.

Җитәкче А.Х.Шәмсетдинов